**Тема: Капма-каршы мәгънәле сүзләр – антонимнар.**
**Максат:**
1.Укучыларның капма-каршы мәгънәле сүзләр – антонимнар буенча белемнәрен ныгыту; аларны табу, сөйләмдә дөрес куллану күнекмәләрен камилләштерү.
2. Халык авыз иҗаты аша укучыларның иҗади фикерләү сәләтен, сөйләм телен үстерү.
3. Укучыларда үз-үзләренә ышаныч, күркәм холык тәрбияләү.

## Дәрес барышы:

### I. Оештыру.

**“И, туган тел, и матур тел,**
**Әткәм-әнкәмнең теле.**
**Дөньяда күп нәрсә белдем,**
**Син туган тел аркылы! (Г.Тукай)**

Хәерле көн, дуслар! Сезне яңадан татар теле дәресебездә күрүемә бик шатмын.

### II. Белемнәрне актуальләштерү.

“Башваткыч” тапшыруы һәммәбезгә таныш, шулай бит, дуслар? Әйе, бу тапшыруны өлкәннәр дә, кечкенәләр дә бик яратып карый. Әйдәгез, үзебезне “Башваткыч”та кунакта итеп хис итик тә, бераз баш ватып алыйк әле.

**Слайд №2 – 8**




**Игътибар экранга! Беренче сорау. 4 хәрефтән торган сүз.**

1. Базарда нәрсә сатылмый икән? (Акыл)
2. Кояш болыт эчендә баеса, явым булыр. Жанры ягыннан бу нәрсә? (Сынамыш)
3. Озын идем - киселдем,
   Юан идем – ярылдым.
   Инде утка тарыдым. (Утын)
4. Ачулану сүзенең синонимын табыгыз. (Орышу)
5. Эш беткәч, ... ярый. (уйнарга)
6. Зи-зи Зилә,
   Ай-яй, зирәк!
   Зирәклек ул бигрәк кирәк. Жанры ягыннан бу нәрсә? (Тизәйткеч)
7. Уңда уймак, табада коймак,
   Мичтә бәлеш, ал да ябыш. Жанры ягыннан бу нәрсә? (Санамыш)

Шакмакларда ачылмаган сүзләр дә калмады. Тапшыру кунакларыннан бер дә ким уйнамадыгыз бит. Вертикаль баганада нинди сүз килеп чыкты? Шулай, антоним сүзе килеп чыкты. Сезгә: “Афәрин!” - диям, укучылар!

**III. Яңа материал буенча эш.**

**Телебез гаять бай, мәгънәләре бер булган сүзләр генә түгел, капма-каршы мәгънәле сүзләр дә күп очрый. Моның шулай икәнлегенә дәрес барышында тагын бер кат инанырбыз, дуслар.**

**Ә хәзер мин кушканның киресен эшләп карагыз әле.**

- Башны уңга борырга (Укучылар сулга боралар)
- Кулларны аска төшерергә. (Укучылар өскә күтәрәләр)
- Башны күтәрергә. (Укучылар төшерәләр)
- Каләмнәрне куярга. (Каләмнәрне алалар)

**Бу эшләрне эшләгәндә, нинди капма-каршы мәгънәле сүзләр килеп чыкты икән? Уң – сул, аска – өскә, күтәрегез – төшерегез, куй – ал. Молодцы!**

**Ә нәрсә соң ул антоним?**

Нәкъ шулай, капма-каршы мәгънәле сүзләр – антонимнар дип атала. Антонимнар капма-каршы күренешләрне, уңай һәм тискәре якларны чагыштырып сурәтләү өчен кулланыла. Грекчадан anti – «каршы», onyma – «исем» дигәнне аңлата. Аларга бер үк сүз төркеменнән булган сүзләр кирәк. Мәсәлән, көн - төн, салкын – кайнар, ала – бирә, кышын – җәен һ.б.

**Слайд №9**




**“Халык әйтсә, хак әйтә”, диләр бит. Антонимнар халкыбыз җәүһәрләре - мәкальләрдә дә үзләренең лаеклы урынын тапкан. Бирелгән мәкальләрдән антонимнарны эзлик әле.**

**Слайд №10-11**




- Гыйлемлек нур – наданлык хур.
- Гыйлем үз иясенә - дус, мал үз иясенә – дошман.
- Укыганга – якты, укымаганга – караңгы.
- Аз сөйлә, күп эшлә.
- Күз куркак, кул батыр.
- Эше әче булса, ашы тәмле булыр.

Гыйлемлек – наданлык, дус – дошман, якты – караңгы, аз – күп, куркак – батыр, әче – тәмле – бу сүзләр барысы да антонимнар.

**Укучылар, сүзләр кайчан антоним була ала? дигән сорауга төгәлрәк җавап бирү өчен, антоним парларның кайсы сүз төркеменә караганын билгелик.**

**Әйе, мәсәлән, туктый - фигыль сүз төркеме, бара шулай ук фигыль сүз төркеме. Әгәр дә сүзләрнең икесе дә бер үк сүз төркеменнән булса, алар антоним була. Ничек уйлыйсыз: нинди сүз төркемнәре антоним була ала?**

- **Шулай: исем, сыйфат, рәвеш, фигыль сүз төркемнәренә кергән**

**сүзләр антоним була ала. Төшенчәләр капма-каршы булып, икесе ике чиктә торсалар гына, антоним сүзләр барлыкка килә. Әлбәттә, капма-каршы сүзләр сүзлек хәзинәбезне баета, сөйләмнең сәнгатьлелеген көчәйтә. Сөйләмдә аларны капма-каршы куеп, чагыштырып карап бирү өчен дә кулланалар.**

**Ә хәзер музыкаль тәнәфес ясап алыйк, дуслар. Мәгълүм бер җырдан өзек тыңларга тәкъдим итәм.**

**Слайд №12**



**- Җыр кем сүзләренә язылган?**

- Шулай, Сәйдә Мөхәммәтҗанова башкаруында М.Җәлилнең «Җырларым» шигыренә язылган җыр бу, укучылар.

Һәркемгә билгеле, М.Җәлил – гражданлык батырлыгы өчен дә, иҗади уңышлар өчен дә югары бәяләнгән тарихи шәхес ул. Укучылар, бу өзектән капма–каршы мәгънәле сүзләрне таба алырбызмы?

Бик дөрес, **үлсәгез һәм яшәсәгез** сүзләре бер-берсенә каршы куелган.

Тагын бер шигъри юллар белән танышып, антоним сүзләрне табыйк әле.

**Слайд №13**




Яхшы сүз шифалы,
Тылсымлы.
Юа ул яраны,
Борчуны.
Яман сүз агудай
Әшәке.
Хәтта ул корыта
Чәчәкне.

Бу сүзләр: яхшы – яман.

**Автор, Галимҗан Латыйп, шигыренең исемендә дә антонимнарны кулланган. “Яхшы сүз, яман сүз” дип атала бу шигырь.**

**Әйе, балалар, болар бик хак әйтелгән сүзләр. Халкыбыз да юкка гына “Яхшы сүз – җан азыгы, яман сүз - баш казыгы” , димәгән бит.**

Алдагы бирем экрандагы рәсемнәр буенча булыр. Рәсемнәргә карап, нинди антонимнар табып булыр икән? Аларны парлап язып алыгызчы.

**Слайд №14-16**




Төгәлләсәгез, тикшереп тә үтик, укучылар. Карт-яшь, кыш-җәй, иртә-кич, көн-төн, юеш-коры, зур-кечкенә диеп язгансыз икән, сез – молодцы!

**Футбол уенын уйнап карамаган кеше сирәктер, дуслар. Ә менә антонимнар белән футбол уйнаганыгыз юктыр әле. Уйныйбызмы? Бик яхшы! Кагыйдәсе гади: сүзнең антонимын дөрес әйткән очракта, капкага гол керәчәк тә инде. Ә мин капкачы!**

Башладык: көн - ..., баллы - ..., бара - ..., аз - ... . Котлыйм! Сез – җинүчеләр!

**Слайд № 17 - 21**




**Сез яраткан тагын бер күңелле шөгыль: табышмаклар әйтү, аларның җавабын эзләү. Аларда да антонимнар бихисап күп очрый, укучылар. Антонимнар кергән нинди табышмаклар беләсез?**

**Слайд № 22**




- Син туктасаң – туктый,
  Син барсаң – бара,
  Ул нәрсә?- Уйлап кара.
  Күләгә шул, дуслар. Антонимнар: туктый – бара.
  Киләсе табышмакның
- Диңгезе бар – балыгы юк,

Каласы бар – халкы юк,
Урманы бар – агачы юк.
Ай-яй, зирәк икәнсез! Карта шул. Антонимнар: бар – юк.

- Җәй шакылдый бу чүкеч,
  Кыш шакылдый бу чүкеч,
  Ничек чыдый бу чүкеч?

Тукран икән бу чүкеч. Антонимнар: җәй – кыш.

**I. Йомгаклау.**

Укучылар, күргәнебезчә, антоним сүзләрне сөйләмебездә дә еш кулланабыз, халык авыз иҗатында аеруча да күп кулланыла икән. Сезгә шундый бирем, дуслар: Н.Исәнбәтнең “Татар халык табышмаклары” китабыннан антонимнар кергән табышмаклар сайлап язып алырга.

**Слайд № 23**

**Дәресебезне Фәнис ага Яруллинның безгә васыять булырлык сүзләре белән тәмамлыйсым килә:** «Тел – халык күңеленең кыңгыравы. Ә кыңгырау - кагылмасаң чыңламый. Әйдәгез, шушы кыңгырауны ешрак кагыйк. Ул тутыкмасын, тавышы гел саф, гел матур булсын, аның моңы еракка яңгырасын».

**Киләсе очрашуларга кадәр, сау булыгыз!**